*Г.Р. Галиуллина*

# БОРЫНГЫ ТӨРКИ ВОКАЛИЗМ ҺӘМ АНЫҢ КЕШЕ ИСЕМНӘРЕНДӘ ЧАГЫЛЫШЫ

**(хезмәт 12-14-16018а / 2012 номерлы проект кысаларында РГНФның финанс ярдәме белән эшләнде )**

Хәзерге татар теленең фонетик системасы, авазлар составы тел үсеше процессында сыйфат һәм сан ягыннан төрле үзгәрешләргә дучар ителүгә карамастан, нигездә борынгы төрки телдә булган төп үзенчәлекләрне саклаган. Бу үзенчәлекләр лексик составның үзәгендә торган төрки чыгышлы сүзләрдә аеруча күзгә ташлана. Төрки телләрнең вокализм өлкәсендә төп билгесе булып, билгеле булганча, сузыклар гармониясе санала. Бу үзенчәлек төрки телләрнең табигатен ачыклауда һәм телләрнең кардәшлеген билгеләүдә дә мөһим роль уйный. Хәзерге төрки телләрдә сузыклар гармониясенең ике төре аерыла: тамыр вокализмы гармониясе һәм морфема вокализмы гармониясе. Сүз тамырының үзенчәлеген һәм лексик тәңгәллекләрне билгеләгәндә, беренче төр төп рольне уйный, чөнки бу төр сузыклар гармониясе үзенең тотрыклылыгы белән аерылып тора. Кулланылыш, төрләнеш үзенчәлегенә карап һәм морфеманың характерына бәйле, морфема вокализмын “көчсез” яисә үзгәрүчән, дип билгелиләр [3: 60].

Һәр төрки телнең яшәеш ареалына һәм табигый үсеш закончалыкларына бәйле, формалашып җиткән һәм яңа лексемалар ясалганда кулланыла торган морфема вариантлары яши. Төрки нигез телдә морфема буларак кулланылган күп кенә элементлар телнең үсеш процессында тамыр составына күчеп, беренчел вариант белән бәйләнешен югалталар һәм бүгенге көндә бу төр сүзләр тамыр буларак карала. Боларга мисал итеп, нигез телдә **а* тамырына морфема берегеп ясалган *апа, ата, ага, ана* кебек туганлык терминнарын китереп була. Шулай ук *куян, арслан, тычкан, каплан* кебек хайван атамаларында да *–ан* морфемасы җиңел аерыла.

Төрки-татар сүзлек составының үзенчәлекле катламын хасил иткән кеше исемнәре системасын борынгы чордан алып бүгенгәчә күзәтү барышында да борынгы төрки вокализмның үсеш-үзгәрешен ачыкларга мөмкин. Әлеге мәкалә кысаларында без космологик төшенчәләр белән бәйле кеше исемнәре мисалында сузыклар гармониясенең нигез телдә һәм хәзерге татар теленә чагылышын анализлау максатын куйдык.

Борынгы төрки телнең антропонимик системасы, билгеле булганча, апеллятив лексика белән турыдан-туры бәйле. Борынгы төркиләрнең табигать белән ныклы бәйләнеше балага исем кушканда ачык чагыла, чөнки әйләнә-тирә яшәеш, аның әһәмиятле үзенчәлекләре, бала туганда күзәтелгән төрле күренешләр исемнәрдә чагылыш тапкан. Шуңа бәйле борынгы төрки исемнәрдә табигать күренешләренең атамалары урын алган. Табигать белән бәйлелек, беренче чиратта, космологик төшенчәләрдә ачык чагыла. Монотеизмның бер төре саналган тәңречелек күкне һәм күк җисемнәрен илаһилаштырган, шул рәвешле кеше исемнәренә бу төр апеллятив лексиканың күчеше барлыкка килгән. Әйтелгәннәргә нигезләнеп, без, кеше исемнәрендә күзәтелгән фонетик үзенчәлекләрне тикшергәндә, апеллятив нигез белән турыдан-туры бәйләнештә караячакбыз.

*Kök* (*күк*) сүзе, мәсәлән, борынгы чорларда ук кеше исемнәре системасына күчкән. Галимнәр фикеренчә, төрки нигез телдә әлеге сүз *каплау* мәгънәсенә ия булган **kö-* тамырыннан барлыкка килгән [4:331]. Борынгы язма истәлекләрдә *Kök Täŋri, Kök* кебек исемнәр кулланылуы мәгълүм. *Ö* авазы – борынгы телдә киң әйтелешле иренләшкән алгы рәт сузыгы, гадәттә сүзнең беренче иҗегендә кулланылган. Хәзерге татар телендә бу аваз *у* гә күчкән (*ö<у). Kök* - *күк,* k*ör* – *күр, tök* – *түк, köl* – *күл* кебек һәм башка шундый тамырлашкан лексемалар моңа мисал булып тора. Ислам дине ныклап таралганчы, әлеге компонент *Күккүз, Күкләш, Күктимер, Күкморза, Күксә* кебек исемнәрдә очрый.

Хәзерге татар телендә *кояш* мәгънәсендә йөри торган борынгы телдәге *kün* сүзеннән *ü<ө* авазлары күчеше нәтиҗәсендә *көн* сүзенә үзгәргән. Хәзерге татар теленең себер татарлары диалектларында, шулай ук урта диалектның Казан

арты сөйләшендә бүген дә бу сүз, фонетик күчеш кичергән хәлдә, борынгы лексик мәгънәсен саклаган [4: 200; 5: 102]. Күренекле тел белгече В.Х. Хаков борынгы телдә әлеге авазны иреннәр катнашында әйтелә торган алгы рәт сузыгы, дип билгели.  Галим күрсәтүенчә, *ӥ* авазы Орхон-Енисей язмаларында сүзнең төрле позицияләрендә урын ала. Шулай ук әлеге авазның сингармонизм законының икенче төренә бәйле, алдагы иҗекләрдәге ныклы позициясен дә күрсәтә [6: 28].

Борынгы антропонимик системада *kün* компоненты катнашып ясалган исемнәр киң таралышта була. Аерым алганда, «Кутадгу билиг» поэмасының төп геройларыннан берсе *Kün-Togdı* исемен йөрткән. Шулай ук борынгы язма истәлекләрдә К*ün, Kün Täŋri* кебек кеше исемнәре дә теркәлгән. Татарларда исә XVIII йөздә дә *Көнтуган, Көнбирде, Көнтумыш, Көнбикә* исемнәре кулланыла[1].

Төрки-татар телендә *ӥ<ө* күчешенә бәйле гарәп һәм фарсы чыгышлы алынма сүзләрдә күзәтелә торган тагын бер үзенчәлекне билгеләп үтә зарур. Әлеге телләрдән кергән сүзләрне, шул исәптән кеше исемнәрен, татар теленә җайлаштыру процессы җанлы сөйләм теле нигезендә барган. Чыганак телдәге кеше исемнәре белән татар теленең фонетик закончалыкларына буйсындырылган вариантны чагыштырып карасак, әлеге күчешкә мисалларны күпләп табарга мөмкин. Мәсәлән, ن□□ □– *Мөэмин;* □□□□ □ – *Һөрия;* □□□ □□ – *Гөлсем/Көлсем* [Гөлсөм/Көлсөм]; موجود– *Мөҗүт* һәм башкалар. Татар теленә фарсы теленнән кергән *гөл* компоненты катнашып ясалган хатын-кыз исемнәренә игътибар итсәк, башка төрки телләрдә бу төр исемнәр гул/гуль вариантында, ә татар телендә исә *[ө]* авазы аша бирелә: мәсәлән, казах телендә – *Гулайым, Гулжахан, Гулшара, Гулбаршын;* үзбәк телендә – *Ғўльчҳера, Олтингуль, Ортигуль;* төрек телендә – *Gülcan, Akgul, Gülgün, Gülay, Gülbahar, Gülruh, Güldeniz, Gülcemal*.

---

[1] Бу хакта тулырак түбәндәге хезмәттән танышырга мөмкин: Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2008. – 349 с.

Төрки нигез телдә үк антропонимик системага күчеп, хәзерге татар кеше исемнәре системасында да үзенең урынын саклаган тагын берничә күк җисеме атамасына тукталыйк. Нигез телдә кулланылган ялтырауның түбән дәрәҗәсен белдергән *jylt-jylt* һәм югары дәрәҗәдәге яктылыкны белдергән *jalt-jalt* аваз ияртемнәре нигезендә барлыкка килгән j*ulduz* сүзе хәзерге татар телендә борынгы мәгънәсендә саклаган хәлдә кулланыла. Фонетик яктан караганда, югары күтәрелешле, иренләшкән *и* авазы тараеп, *о* авазына күчкән: *йолдыз* [*Йолдоз*]. Мондый күчеш телнең күмәклек сүзләрендә тагын да киңрәк күзәтелә: *ич̌* - *оч, ut – от, qul – кол, kut – кот, kur (и) – кор(у).* Бу үзенчәлек сүзнең беренче иҗегендә яисә бер иҗекле сүзләрдә очрый [6: 26]. Борынгы телдә күзәтелгән иренләшү гармониясе *(uruş, uzun, ičuz)* хәзерге татар теленең орфоэпик нормалары нигезендә *о* авазына бәйле дәвам итә: [*орош*], [*озон*], [*очсос*] һ.б. *Йолдыз* апеллятивына нигезләнеп ясалган кеше исеме хәзерге татар телендә дә шактый активлардан санала һәм үзенең бинар табигате, ягъни һәм ир балаларга, һәм кыз балалаларга кушылуы белән билгеле. Әлеге исем төрле фонетик вариантларда күп кенә төрки телләрдә кулланыла, мәсәлән, татарларда *Йолдыз*, башкорт телендә – *Йондыз*, төрек телендә – J*ulduz*, кыргыз телендә – *Җулдуз* һ.б.

Венера йолдызының төрки атамасы шулай ук кеше исемнәре системасында шактый борынгыдан билгеле. Нигез телдәге **čolpan* варианты хәзерге татар телендә *у* (у<о) авазына күчү нәтиҗәсендә *Чулпан* вариантында кулланыла. Г.Ф. Благова әлеге сүзнең килеп чыгышын *čolp*+фигыль ясагыч *–у* һәм сыйфат фигыль кушымчасы *–уan* ярдәмендә ясалган, дип аңлата [1: 335]. Борынгы телдә киң әйтелешле, урта күтәрелештәге иренләшкән әлеге калын сузык аваз сүзнең беренче иҗегендә кулланылган: *on, bol, otun, orun, čortan, orta* һ.б.

*Чулпан* исемендә борынгылык сакланышын хәзерге якут (*Чолбон*), хакас (*Солбан*), уйгур (*Чолпон*), казах (*Шолпан*), кыргыз (*Чолпан*), төрекмән (*Чолпан*) телләрендә очратабыз.

Шулай итеп, сузык авазлар өлкәсендә күзәтелгән авазлар күчеше телнең төрле катламнарында күзәтелә. Шул ук вакытта, космологик төшенчәләрне

белдергән сүзләр һәм алар нигезендә ясалган кеше исемнәрендә сузыклар күчешен исәпкә алган хәлдә, тамыр вокализмының шактый тотрыклы булуы ачыкланды.

ӘДӘБИЯТ:


1. Благова Г.Ф. Антропонимическая система как проекция космологических и социальных представлений пратюрков // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. М.: Наука, 2006. – 660-754
2. Моллова М. К истории тюркского вокализма // Вопросы языкознания. – №2. – М.: Наука, 1966. – С.57- 66
3. Мусаев К.М. Очерки по реконструкции картины мира пратюркского этноса по данным языка // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира пратюркского этноса по данным языка. – М.: Наука, 2006. – С.326-336
4. Татар теленең диалектологик сүзлеге / Төз.: Ф.С. Баязитова, Д.Б. Рамазанова, З.Р. Садыйкова, Т.Х. Хәйретдинова.— Казан: Татар китап нәшр., 1993. – 459б.
5. Тумашева Д.Г. Словарь диалектов сибирских татар. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1992 – 255с.
6. Хаков В.Х. Тел – тарих көзгесе. – Казан: Татар. китап нәшр., 2003. – 294б.